КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 24 февраль г.Казань № 158

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 20076 ел, 23 июль, 325 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Икътисад министрлыгы мәсьәләләре» 2007 ел, 23 июль, 325 нче карары (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2009 ел, 23 гыйнвар, 31 нче; 2009 ел, 24 сентябрь, 659 нчы; 2010 ел, 10 сентябрь, 729 нчы; 2010 ел, 17 декабрь, 1078 нче; 2011 ел, 17 гыйнвар, 15 нче; 2011 ел, 13 август, 676 нчы; 2012 ел, 3 февраль, 81 нче; 2012 ел, 18 октябрь, 871 нче; 2012 ел, 24 декабрь, 1139 нчы; 2012 ел, 31 декабрь, 1192 нче; 2013 ел, 14 март, 159 нчы; 2013 ел, 8 апрель, 238 нче; 2013 ел, 4 июнь, 384 нче; 2013 ел, 4 октябрь, 715 нче; 2013 ел, 31 октябрь, 818 нче; 2014 ел, 13 август, 590 нчы; 2014 ел, 11 ноябрь, 854 нче; 2015 ел, 20 март, 174 нче; 2015 ел, 4 июнь, 407 нче; 2016 ел, 28 гыйнвар, 44 нче; 2016 ел, 6 август, 533 нче; 2016 ел, 12 декабрь, 918 нче; 2017 ел, 21 март, 168 нче; 2017 ел, 12 сентябрь, 649 нчы; 2018 ел, 1 декабрь, 1070 нче; 2018 ел, 10 декабрь, 1093 нче; 2019 ел, 11 сентябрь, 814 нче; 2019 ел, 22 ноябрь, 1065 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1253 нче; 2019 ел, 30 декабрь, 1263 нче; 2020 ел, 15 гыйнвар, 6 нчы; 2020 ел, 6 март, 180 нче; 2020 ел, 31 август, 759 нчы; 2020 ел, 22 сентябрь, 853 нче; 2020 ел, 22 декабрь, 1177 нче; 2021 ел, 12 февраль, 71 нче; 2021 ел, 17 июнь, 466 нчы, 2021 ел, 15 декабрь, 1238 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) белән расланган Татарстан Республикасының

Икътисад министрлыгы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4.1.41 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1.41. «Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 7 өлешендә каралган капитал салуларны яклау һәм бүләкләү өлкәсендәге вәкаләтләрне Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашыра:

аңа кушымта итеп бирелә торган документлар һәм материаллар белән капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешү төзү хакындагы гаризаны карый;

Татарстан Республикасы исеменнән капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешүләргә һәм аларга өстәмә килешүләргә имза сала;

капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында һәм шулардан килеп чыга торган бәхәсләрне җайга салу турында килешүләрне үзгәртү һәм гамәлдә булуын туктату турында карарлар кабул итә;

мондый килешү төзелгән инвестиция проектын, шул исәптән инвестиция проектын гамәлгә ашыру этапларын да, капитал салуларны һәм гамәлгә ашыру шартларын яклау һәм бүләкләү турындагы килешүнең шартларын мониторинглауны үткәрә;

«Россия Федерациясендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында» 2020 елның 1 апрелендәге 69-ФЗ номерлы Федераль законның 4 статьясындагы 1 өлешенең 7 пункты нигезендә раслана торган чыгымнарны кайтару тәртибе нигезендә капитал салуларны яклау һәм бүләкләү турында килешү кысаларында гамәлгә ашырыла торган инвестиция проектын гамәлгә ашыра торган оешма тарафыннан тапшырыла торган документларны аларның комплектлылыгы предметына тикшерә.»;

түбәндәге эчтәлекле $4.1.41^1$ пункт өстәргә:

«$4.1.41^1$. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъекты бюджеты акчаларын гамәлгә ашыру максатларында бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе алдындагы Россия Федерациясе субъекты алдындагы бурычны түләү күләмен киметү нәтиҗәсендә бушатыла торган Россия Федерациясе субъекты тарафыннан инфраструктура объектларына бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашыруга җибәрелергә тиеш яңа инвестиция проектларын билгеләү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 19 октябрендәге 1704 номерлы карары нигезендә яңа инвестиция проектларын сайлап алу һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе субъектының Россия Федерациясе алдындагы бурычларын юкка чыгару кагыйдәләрен, яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан федераль бюджетка салым керемнәре керүне исәпләү методикасын һәм федераль бюджетка яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан салым керемнәре исемлекләрен кертү буенча Россия Федерациясе Хөкүмәте бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе субъектларының бурычларын сызып ташларга хокуклы яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан федераль бюджетка күчерелергә тиешле салым керемнәре исемлеген раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 октябрендәге 1705 номерлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында» 2021 елның 12 октябрендәге 1740 номерлы карары нигезендә бюджет кредитлары буенча Россия Федерациясе

алдындагы Татарстан Республикасы бурычларын исәптән чыгару мәсьәләләре буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

яңа инвестиция проектларын сайлап алу, бюджет кредитлары буенча Россияй Федерациясе алдындагы Татарстан Республикасы бурычларын исәптән чыгару мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының үзара хезмәттәшлеген координацияли;

инвестиция проектларының җыелма исемлегенә кертелгән яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашыру турында килешүләргә имза салу буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы була;

яңа инвестиция проектларының төгәлләштерелгән исемлеге проектын төзи;

яңа инвестиция проекты кысаларында элек теркәлгән юридик зат тарафыннан җитештерелгән товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатудан табыш (керем) өлешен, Россия Федерациясе Салым кодексының 249 статьясы нигезендә билгеләнә торган товарларны (эшләрне, хезмәт күрсәтүләрне) сатудан алынган табышларны (керемнәрне) исәпләү методикасын раслый, тулаем оешма буенча;

федераль бюджетка яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан салым керемнәре турында җыелма мәгълүматлар формалаштыра, аларның кертемнәре күләмендә Россия Федерациясе Хөкүмәте бюджет кредитлары буенча Татарстан Республикасының бурычларын түләргә хокуклы;

яңа инвестиция проектларын, документларны һәм белешмәләрне гамәлгә ашыручы элек теркәлгән юридик зат тарафыннан яңа инвестиция проектларын гамәлгә ашырудан керемнәр суммасының дөреслеген раслау максатларында Федераль казначылык тарафыннан мондый юридик затның финанс-хуҗалык эшчәнлеген гамәлгә ашыру буенча тикшерү чараларын уздыру өчен кирәкле мәгълүматны тапшыруны тәэмин итә;

яңа инвестиция проектын, Россия Федерациясе Салым кодексының 102 статьясында каралган килешүне гамәлгә ашыручы элек теркәлгән юридик зат тарафыннан салым органына яңа инвестиция проектын гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә әлеге юридик зат тарафыннан түләнгән салымнар һәм җыемнарның гомуми күләме өлешендә белешмәләр кертүне тәэмин итә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин